ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
2. 2019 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры хисабы.
3. 2019 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлеше турында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.
4. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 44-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 48-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 51-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 47-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 49-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 45-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 46-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Инновацион транспорт чаралары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

12. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

13. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмәсе турында.

14. Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.

15. «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ант итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның 9 июнендәге 3617-IV ДС номерлы карарына үзгәреш кертү хакында.

16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Кәримов Габделхәй Йосыф улының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

17. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 50 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 883717-7 номерлы федераль закон проекты хакында (файдалы казылмаларны чыгаруга салымны исәпләү нормативларын яңадан бүлү өлешендә (углеводород чималы төрендәге файдалы казылмалардан, табигый алмазлардан һәм гомумтаралган файдалы казылмалардан тыш).

18. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $179^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 875578-7 номерлы федераль закон проекты хакында (федераль әһәмиятле гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлыннан йөргән өчен түләү турындагы законнарны үтәмәгән өчен штрафлар исәпләү өлешендә).

19. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр хакында тыелган мәгълүмат урнаштырган (тараткан) өчен җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 876368-7 номерлы федераль закон проекты турында.

20. «Россия Федерациясе Су кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» 860875-7 номерлы федераль закон проекты хакында (эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклау зоналары чикләрендәге торак пунктлар территорияләрендә хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тыюны бетерү өлешендә).

21. «Россия Федерациясендә торак фондын реновацияләү турында» 825313-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

22. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 29 һәм 40 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 875582-7 номерлы федераль закон проекты хакында (түләүле автомобиль юлларыннан йөргән өчен түләү турында).

23. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законның 4 һәм 4.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 854326-7 номерлы федераль закон проекты турында (кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертү шартлары хакында).

24. «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясына кинотеатрларда фильмнарны күрсәтү алдыннан рекламаның дәвамлылыгын чикләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 871109-7 номерлы федераль закон проекты турында.

25. «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 877880-7 номерлы федераль закон проекты турында (турагентлык эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә).

26. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законының $42^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ростов өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

27. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 30 статьясына үзгәреш кертү хакында» 865129-7 номерлы федераль закон проекты турында (күзәтүче юлламасы бирү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

28. «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның $12^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 892401-7 номерлы федераль закон

проекты турында (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу тәртибен җайга салу).

29. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның $71^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 868839-7 номерлы федераль закон проекты турында (югары белем бирү уку-укыту программалары буенча максатчан укытуга кабул итү үзенчәлекләрен төгәлләштерү өлешендә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
урынбасары Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2020 елның 13 феврале
№ 261-VI ДС